РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

БОЛЬШЕШИНАРСКИЙСЕЛЬСКИЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422054, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Большой Шинар, ул. Кооперативная, 36
тел. (84362) 41-2-11

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ОЛЫ ШЫҢАР АВЫЛ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422054, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Олы Шыңар авылы, Кооператив урамы, 36 йорт
тел. (84362) 41-2-11

e-mail: bshin.sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР
29.06.2020 | № 17-п

Олы Шыңар авыл Башкарма комитетының
16.05.2016 елның 24-п номерлы
«Муниципаль торак контролен тормышка
ашырганда тикшерүләр үткәрүнең
административ регламентын раслау турында"
карарына үзгәрешләр кертү турында

Район прокуратурасының 19.06.2020 елның 02-08-02-87-2020 номерлы протесты һәм "Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында" 02.12.2009 ел, №390-ФЗ Федераль закон нигезендә Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Олы Шыңар авыл Башкарма комитетының 16.05.2016 елның 24-п номерлы « Муниципаль торак контролен тормышка ашырганда тикшерүләр үткәрүнең административ регламентын раслау турында» карары белән расланган муниципаль торак контролен тормышка ашырганда тикшерүләр үткәрү буенча административ регламентка түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.1 пунктны киләсе эчтәлектәге 3.1.1 пункты белән тулыландырырга:

"3.1.1.Планлы тикшерүнең еллык планына планлы тикшерүләрне кертү өчен нигез булып кабул иткән көннән бер ел үтү тора:

- дәүләт торак күзәтчелеге органына тапшырылган уведомлениегә туры китереп, торак милекчеләре ширкәте, торак, торак-тезелеш кооперативы яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы тарафыннан күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлау;
- социаль файдаланудагы беренче наемга алынган торак йортның социаль файдаланудагы наемга алынган йортларның муниципаль реестрында исәпкә кую , торак урыннарны наймлаучы , эшчәнлеге тикшерелергә тиешле зат булырга тиеш.
- юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата соңгы планлы тикшерүне үткәрү тәмамлануы;
- коммуналь ресурсларны (коммуналь хезмәтләрне) куллану нормативларын билгеләү һәм үзгәртү.".

2. Әлеге карарны«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://saby.tatarstan.ru/shinar, бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Олы Шыңар авыл җирлеге башлыгы: А.Г.Гарипов